СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД АГРЫЗ» АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

22.04.2026 Әгерҗе ш. № 7 - 7

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 13 декабрендәге 28-2 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексын раслау хакында» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы РЕШИЛ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 13 декабрендәге 28-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. бүлегендә:

1.1.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә**:**

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан, муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда белешмәләрне тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм формада тапшырыла.»;

1.1.2. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар

чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча белешмәләр тапшырырга тиеш..»;

1.1.3.3 пунктта «2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1.4 пунктта «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктта «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр» сүзләрен «муниципаль хезмәткәрләргә әлеге пункт нигезендә бирелә торган белешмәләр,» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләрен «муниципаль хезмәткәрләргә әлеге пункт нигезендә тапшырыла торган белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;»;

1.1.7. 7 пунктта «үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләрен «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законда каралган чыгымнар хакында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга.,»;

1.1.8. 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыра, мондый вазыйфаны биләүче зат әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән белешмәләрне Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгы (Раиса) тарафыннан тапшыра.»;

1.1.9. 12 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

14 пунктта «2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 20 бүлекнең 3 пунктындагы 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиягә йөкләргә..

Советы Рәисе
Муниципаль берәмлек башлыгы Л.Ф. Нургаянов